РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БАЮКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МУСЛЮМОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАЕК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

---

«22» апрель 2024 ел　　Баек авылы　　№ 7

**«Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләр үсү урыннарын ачыклау һәм юк итү чаралары турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Башкарма комитетының «01» февраль 2024 елдагы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге Башкарма комитеты

**КАРАР БИРӘ:**

1. «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының Баек авыл җирлеге территориясендә кыргый наркотиклы үсемлекләрнең үсү чыганакларын ачыклау һәм юкка чыгару чаралары турында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитетының «01» февраль 2024 елгы карарының 1 нче кушымтасына үзгәрешләр кертергә һәм 1 нче кушымта нигезендә наркотик булган үсемлекләрне ачыклау һәм бетерү буенча эшче төркем составын бәян итәргә.

2. 4 бүлекнең 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«9. Эшче төркем утырышлары елына кимендә ике тапкыр уздырыла, июнь-сентябрь айларында.».

3. Әлеге карарны Мөслим муниципаль районы муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән гамәлгә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Баек авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе:　　М.Ф.Фахерлегаянов

Баек авыл җирлеге җитәкчесенең
«22»апрель 2024 ел 7 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Баек авыл җирлеге территориясендә кыргый, наркотиклы үсемлекләрне ачыклау һәм юк итү буенча эшче төркем составы**

**Эшче төркем рәисе:**

М.Ф.Фахерлегаянов - Баек авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе:

**Эш төркеме сәркатибе:**

Хамадишина И.М. - Баек авыл җирлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары

**Эшче төркем әгъзалары:**

Нуриева Резеда Марселевна –Баек авылы мәдәният йорты директоры (килешү буенча).